РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ЯКУШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Якушкино
ав.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«12» ноябрь 2021 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 25 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Салдакай авылы, Үзәк урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча К.Маркс урамында яшәүче гражданнар өчен халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2021 елның 26 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Салдакай авылы, Үзәк урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Комсомол, Лермонтов, Октябрь, Пушкин, Үзәк урамында яшәүче гражданнар өчен халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылында яшәүчеләрнең гражданнар җыенын үткәрү өчен исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2022 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Салдакай авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм ремонтлау;

Салдакай авылында янгын сүндерү машинасы өчен җылы гаражны ремонтлау һәм җиһазлау;

Салдакай авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау,

шул исәптән сезонлы карап тоту».

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Салдакай авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге башлыгы Хәмидуллин Х.Х.